КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 гыйнвар г.Казань № 47

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибен раслау турында» 2010 ел, 29 гыйнвар, 44 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибен раслау турында» 2010 ел, 29 гыйнвар, 44 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 28 май, 418 нче; 2010 ел, 6 сентябрь, 713 нче; 2011 ел, 4 март, 172 нче; 2011 ел, 31 октябрь, 895 нче; 2012 ел, 30 гыйнвар, 59 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1185 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү (файдалану, кире кайтару) тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

11 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль берәмлек кредит оешмаларыннан Россия Федерациясенең Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән, 1 елга бер процентка арттырылган төп ставка дәрәҗәсенә караганда югарырак ставкалар буенча муниципаль берәмлек бюджетына кредитлар җәлеп итмәскә дигән йөкләмәне үз өстенә ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин